ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның 24 гыйнары Балык Бистәсе штп. № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Балык Бистәсе штп. өчен җирле гражданнар җыенында кабул ителгән 2022 елның 21 ноябре 1 номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 48А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендына һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Дадукова Р.Р. йөкләргә.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе шәһәр
җирлеге Башкарма комитетының
2022 елның 24 гыйнвары
2 номерлы карары
белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм тыл хезмәтчәннәреннән, Россия Федерациясе Президенты В.В. Путин игълан иткән өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә 2023 елның 28 февраленә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“Балык Бистәсе шәһәр җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
җыю Тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге”
муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и. ____________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
______________________________________________________________нигезендә
Сезгә 2023 елның 28 февраленә кадәр_______________________________________
________________________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: ____________________________________________________
БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк
_______________________________________
Сч. № __________________________________
Сч. № алучы__________________________________________
ИНН _____________________________________________
КПП _________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләүнең билгеләнеше
________________________________________________________________________
__

Җитәкче __________________ ________________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - -**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган _________________сум күләмендәге түләүне түләү турында ХӘБӘРНАМӘ №_________
Түләүченең Ф.И.А.и. ____________________________________________________
Адрес:_______________________________________________________________
Алдым “____” _______________, 20__ ел

_______________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм _______________җирлеге Башкарма комитетында кала.*